Кулланучы хәбәрләре

# Өйдә кем хуҗа?

## Фатир хуҗалары үз йортлары белән идарә итү алымын сайларга тиеш.

**Күп фатирлы йорт белән идарә итү буенча стандартлар һәм эшчәнлек кагыйдәләре, шулай ук хезмәт һәм эшләрнең минималь исемлеге составы, аларны күрсәтү һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Узган елның декабрендә торак законнарында кайбер үзгәрешләр булды.**



РФ Торак кодексы нигезендә, күп фатирлы йорт белән идарә итү анда яшәүче гражданнарга уңайлы һәм имин шартлар, гомуми милекне тиешенчә карап тоту һәм алардан файдалану мәсьәләләрен хәл итүне, шушы йортта яшәүче гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне, гомуми милек составына керә торган инженер коммуникацияләре һәм башка төрле җиһазларның даими әзерлеген тәэмин итәргә тиеш.

Күп фатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге, торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яки башка төрле махсуслашкан кулланучы кооперативы һәм РФ Торак кодексының 200 маддәсе 3 өлешендә каралган очракта, мондый эшчәнлекне башкарудан тыш, аны алып бару өчен бирелгән лицензия нигезендә башкарыла.

2020 елның 22 декабрендә кабул ителгән «РФ Торак кодексының 161нче маддәсенә үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон (№ 441-ФЗ) нигезендә, РФ Торак кодексының 161 маддәсе 17 өлешенә үзгәрешләр кертелде. Хәзер, әгәр күп фатирлы йортта яшәүчеләр йорт белән идарә итү алымын сайламаса, ул чагында җирле үзидарә органы идарәче оешманы билгеләү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр биш эш көне дәвамында күп фатирлы йорттагы барлык милекчеләргә югарыда аталган карарны кабул итү, бу йорт белән идарә итү килешүен төзү шартлары һәм әлеге идарәче оешма белән идарә итү килешүен өзү шартлары хакында язма рәвештә хәбәр итә.

**Күп фатирлы йорт белән идарә итү килешүе җирле үзидарә органы тарафыннан идарәче оешманы билгеләү турында карар кабул ителгән көннән төзелгән дип санала.**

# Менюда – ит, ә тәлинкәдә... балык

**«Улым III сыйныфта укый. Бүген аңа нәрсә ашатачаклары минем өчен һәрвакытта да кызык. Әмма мәктәп сайтындагы меню һәрвакытта да чынлыктагы менюга туры килми. Мәктәптә тәкъдим ителгән менюдагы ашамлыкларны алыштырырга ярыймы?**

**Ирина П.»**

Чынлыктагы туклану рационы расланган менюга туры килергә тиеш. СанПиНның 6,22 пунктында 2.4.5.2409-08 («Гомуми белем бирү учреждениеләре, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр») шул хакта сүз бара.

Менюдагы ризыклар, ашлар һәм кулинария әйберләрен гадәттән тыш очракларда һәм мәҗбүри шартлар үтәлгәндә генә башкаларына алыштырырга рөхсәт ителә. Аларның азык кыйммәте бердәй булырга һәм азык-төлек продуктларын алыштыру таблицасына (санитар кагыйдәләрнең 6 кушымтасы) тәңгәл килергә тиеш. Моның тиешле хисаплар белән раслануы шарт. Әйтик, мәктәпкә тиешле чималны үз вакытында китермәү сәбәпле, сыер итеннән кәтлит әзерли алмасалар. Бу очракта 100 грамм



сыер итен (аксым буенча бердәй күләмдә), 13 грамм ак май өстәп, 120 грамм балык (кылчыксыз тәрәч) белән алыштырырга мөмкин. Шулай ук эремчек һәм йомыркадан әзерләнгән ризыклар белән дә алмаштырып була.

| Итне алыштыру (аксым буенча) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Сыер ите (1 кат.)** | 100 | 18,6 | 14,0 | | |
| **Сыер ите (2 кат.)** | 90 | 18,0 | 7,5 | | Май +6 г |
| **Ярым майлы эремчек** | 110 | 18,3 | 9,9 | | Май +4 г |
| **Майлы эремчек** | 130 | 18,2 | 23,4 | 3,7 | Май -9 г |
| **Балык (кылчыксыз тәрәч)** | 120 | 19,2 | 0,7 | - | Май +13 г |
| **Йомырка** | 145 | 18,4 | 16,7 | 1,0 | |

Шуның белән бергә, менюда шул ук көнне яки алдагы 2-3 көнне бер үк ризыклар яисә кулинария әйберләре кабатланмаска тиеш (СанПиНның 6.13 пункты, 2.4.5.2409-08).



Реклама

# «Безнең Маша»

## Президент «ШАЯН»нарның хыялын тормышка ашырды

**2018 елның 12 ноябрендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов беренче татар балалар телеканалы эшчәнлегенә тантаналы рәвештә старт биргән иде. Ә ике елдан соң Президент өр-яңа студиябезгә кунакка килде.**

Шушы вакыт эчендә каналыбыз үсте, камилләште, төрле казанышларга һәм җиңүләргә ия булды. Эфирга дистәләгән проект һәм йөзләгән мультсериал чыкты. Әле кайчан гына камера күргәч оялып торган балалар – хәзер үз эшләренең осталары һәм каналның хуҗалары!

Бу көн «ШАЯН ТВ» телеканалы тарихына зур вакыйга булып кереп калыр. Ниһаять, бөтендөнья татар балаларына ясаган олы бүләге өчен, Рөстәм Нургалиевичка рәхмәт белдерергә, аны үзебезнең уңышлар, яңа проектлар белән таныштырырга җай чыкты.

Мөхтәрәм кунагыбызны каналның төп геройлары каршы алды. Студия буенча экскурсияне дә балалар үзләре үткәрде. Тапшырулар ничек әзерләнә? Режиссер, оператор, монтаж ясаучыларның эше нәрсәдән гыйбарәт? Яшь алып баручылар Президентка барысы хакында да бәйнә-бәйнә сөйләделәр.

Каналның контентын баетуга «ШАЯН ТВ»ның дубляж студиясе зур өлеш кертә. Рөстәм Миңнеханов әлеге мәйданчыкны да игътибарсыз калдырмады. Президент «Маша белән Аю» мультсериалын тавышландыру барышын күзәтте, яшь йолдызчыгыбыз Зәлия белән танышты. Соңрак инстаграмына, «Безнең Маша» дип, фото да урнаштырды.

Президентның игътибарын аеруча телевизион блогерлар мәктәбе җәлеп итте. Рөстәм Миңнеханов үзе дә социаль челтәрләрдә шактый актив. Аның инстаграмдагы шәхси сәхифәсен 530 меңнән артык кеше күзәтеп бара.

Яшь журналистлар өчен иң күңеллесе – Президенттан интервью алу. Аларның Республика башлыгына сораулары шактый җыелган. Әңгәмә барышында Рөстәм Миңнеханов заманча трендлар, гаджетлар, ТикТок социаль челтәре хакында фикерләре белән уртаклашты.

Рөстәм Миңнехановка, балаларга карата игътибарлы, киң күңелле булганы өчен, «ШАЯН ТВ» каналы исеменнән чиксез рәхмәтебезне белдерәбез! Әлеге очрашу – балаларның зур теләге иде. Республика башлыгы аларның күптәнге хыялын тормышка ашырды.

**ТАШЛАМАЛЫ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫП КАЛ!**

**«Шәһри Казан» газетасына икенче яртыеллыкка ташламалы бәядән язылып калырга өлгерегез!**

Чәршәмбе чыга торган (индексы – П2430) санының ярты елга язылу бәясе нибары 503,28 сум гына. «Шәһри Казан» – гади, үтемле, гыйбрәтле, кызыклы, тормышчан газета!

Реклама

Аттестат об основном общем образовании А-097289, выданный МБОУ «Школа №82» в 1994 году на имя Зайнуллина Рафаэля Миннуровича, считать недействительным в связи с утерей.

БӨТЕН КЫЗЫКЛЫ МӘГЪЛҮМАТ БЕР УРЫНДА
shahrikazan.ru

Реклама